**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**

422370 г.Тетюши, ул.Малкина, 39

422370 Тәтеш шәһәре, Малкин ур, 39

тел. (84373) 2-50-02, 2-53-33, факс 2-62-48, e-mail: tatesh@tatar.ru
ОКПО 78702097, ОГРН 1061672000037, ИНН/КПП 1638004978/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**30 .09. 2024** **№ 53-2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, җирле үзидарә органнары карарлар кабул иткәндә халык фикерен ачыклау һәм аны исәпкә алу максатларында Тәтеш муниципаль районы җирле үзидарә вазыйфаи затлары, Тәтеш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.
2. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында "2010 елның 29 декабрендәге 5-16 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

**Татарстан Республикасы
Тәтеш муниципаль районы
Башлыгы вазифаларын башкаручы** **Е.Г. Курков**